**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

Урсай авылы № 130 январь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе турында" 2010 ел 12 ноябрь 8 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2012 елның 30 март 42 номерлы, 2017 елның 28 февральдагы 52 номерлы карарлар редакциясендә)

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары нигезендә,

Урсай авыл җирлеге Советы **карар чыгарды**:

1. Урсай авыл җирлеге Советының 2009 елны 172-ФЗ «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе турында» 8 номерлы карары (2012 елның 30 март 42 номерлы, 2017 елның 28 февральдагы 52 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Граждан җәмгыяте институтларына һәм Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - гражданнар) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган тәртиптә үз акчалары исәбенә норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) бәйсез коррупциягә каршы экспертиза уздыра алалар. Норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) экспертиза үткәрү буенча экспертларны аккредитацияләү тәртибе һәм шартлары юстиция өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә.

Норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектлары) Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү рөхсәт ителми):

1) хөкем ителгән яки бүгенге көндә хөкем астыныды булган гражданнар;

2) коррупциячел хокук бозулар кылган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән (вазыйфасыннан азат ителгән) затлар реестрына кертелгән гражданнар;

3) әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән органнар һәм оешмаларда эшчәнлекне гамәлгә ашыручы гражданнар;

4) халыкара һәм чит ил оешмалары;

5) Чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерцияле булмаган оешмалар.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим рәвешендә бирелә һәм ул Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан, аны алган көннән алып 30 көн эчендә, мәҗбүри каралырга тиеш. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән гражданга яки оешмага мотивацияләнгән җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат, яисә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен һәм (яисә) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый актта ачыкланган коррупциоген фактор белән килешмәү сәбәпләрен исәпкә алу чагылдырыла.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 17,18,19, 20 пунктлар өстәргә:

«17. Дәүләт сере яисә җирле үзидарә органы (вазыйфаи зат) конфиденциаль характердагы белешмәләр булган проектлардан тыш, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен әлеге документларны әзерләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итүне башлау һәм тәмамлау даталарын, электрон почта адресын, кабул итү көнен күрсәтеп Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыра: http://aznakayevo.tatasrstan.ru.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы биш эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

18. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча методика нигезендә рәсмиләштерелә торган эксперт бәяләмәсе төзелә.

Эксперт бәяләмәсе документны эшләүче җирле үзидарә органына (вазыйфаи затка) почта, курьер белән яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Татарстан Республикасы рәсми порталында «Бәйсез коррупциягә каршы экспертиза» электрон сервисын кулланып бәйсез антикоррупцион экспертиза үткәрелгән очракта, бәяләмә Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан 2014 елның 9 июлендәге 01/5026 номерлы «Бәйсез коррупциягә каршы экспертиза» электрон сервисы белән эшләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы рәсми порталына җибәрелә.

19. Бәяләмәдә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча норматив хокукый актта (норматив хокукый акт проектында) ачыкланган коррупциоген факторлар күрсәтелергә һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителергә тиеш.

20. Дәүләт серен тәшкил итүче норматив хокукый актлар яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлардан тыш,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы _________ авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Азнакай муниципаль районы _________ авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының кабул ителгән норматив хокукый актларын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыралар: http://aznakayevo.tatasrstan.ru.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырыга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.А.Абдуллин

УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ